РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**КАРАР**

7 август 2018 ел Буа шәһ. № 9-33

ТР Буа муниципаль районында
муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү турында

02.03.2007 елгы 25-ФЗ номерлы «РФ муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, 02.03.2007 елгы 25-ФЗ номерлы «РФ муниципаль хезмәт турында», 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы «РФ җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законнар, 01.07.2017 елгы 132-ФЗ номерлы “РФ аерым закон актларының коррупцион хокук бозган өчен ышанычны югалту белән бәйле эштән азат итүне җәза итеп куллану турында мәгълүматны дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт информацион системасында урнаштыру өлешенә үзгәрешләр кертү турында” Федераль законнар, 25.06.2013 елгы 50-ЗРТ номерлы “Муниципаль хезмәт турында” ТР Кодексы нигезендә, һәм муниципаль норматив хокук актын законга туры китерү максатында, ТР Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2017 елның 6 июлендәге 3-22 номерлы Буа муниципаль районы Советы Карары (в редакции Решения от 11.12.2017 елгы 7-27 номерлы, 24.04.2018 елгы 7-31 номерлы Карар редакциясендә) белән расланган ТР Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

**1.1. Нигезләмәнең 7 Бүлеге:**

**7 пунктның 2 пункт астын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:**

“2) муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазифалары буенча - муниципаль хезмәт стажының ике елдан да ким булмавы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажының дүрт елдан да ким булмавы;

муниципаль хезмәтнең төп вазифалары буенча - муниципаль хезмәт стажының бер елдан да ким булмавы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажының ике елдан да ким булмавы.”;

**7.2 пункт 2 пункт астының 5 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:**

“Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы, өлкән һәм кече төркемнәре өчен вазифаларны алмаштыру өчен муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификацион таләпләр билгеләнми.”;

түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Әгәр муниципаль хезмәткәргә вазифаи инструкция белән белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата муниципаль хезмәт вазифасын алмаштырырга кирәк булган таләпләр каралган очракта, белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, күрсәтелгән стажга гражданин (муниципаль хезмәткәр) белем алу турында һәм (яки) күрсәтелгән белгечлек, әзерлек юнәлеше турында документ алганнан соң, бу белгечлек, бу әзерлек юнәлеше буенча эшләү чоры керә.”;

түбәндәге эчтәлектәге 8 абзац белән тулыландырырга:

«Әгәр муниципаль хезмәткәргә вазифаи инструкция белән белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата муниципаль хезмәт вазифасын алмаштырырга кирәк булган таләпләр каралмаган очракта, белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, күрсәтелгән стажга гражданин (муниципаль хезмәткәр) муниципаль хезмәт вазифасын алмаштыру өчен квалификацион таләпләргә туры килгән дәрәҗәдәге һөнәри белем турында документ алганнан соң, аңа муниципаль хезмәт вазифасында вазифаи йөкләмәләрне үтәү өчен кирәкле белем һәм күнекмәләр алынган эш чоры керә.”;

7.6 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

7.6. Белгеч яки магистр кызыл дипломлы затлар өчен диплом биргән көннән алып өч ел дәвамында муниципаль хезмәт стажына яки муниципаль хезмәтнең төп вазифаларын алмаштыру өчен белгечлек буенча эш стажына квалификацион таләпләр билгеләнә - муниципаль хезмәт стажы ярты ел яки белгечлек буенча эш стажы бер ел булырга тиеш.

**1.2. Нигезләмәнең 14 Бүлеге:**

14.2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

«Авыл, шәһәр округында урнашкан авылларда җирле администрация вәкаләтләренең бер өлешен башкару йөкләнгән җирле администрация территориаль органының җитәкчесе вазифасын алмаштыруга конкурс үткәрелгән очракта, муниципаль берәмлектә конкурс комиссиясен формалаштыру тәртибендә аның әгъзалары санына әлеге авылларның һәрберсендә гражданнар җыелышы тәкъдим иткән кандидатуралар керү каралырга тиеш.”;

**1.3. Нигезләмәнең 20 Бүлеге:**

20.4 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«Муниципаль хезмәткәргә закон нигезендә, дәүләт сере булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен, вазифа окладына һәр айлык өстәмә акча билгеләнә.»;

1.1 Нигезләмәнең 22 Бүлеге:

22.6 пунктны түбәндәге редакциядә биреп өстәргә:

«22.6 Муниципаль хезмәткәргә карата ышанычны югалту белән бәйле эштән азат итү җәзасын куллану турындагы мәгълүмат муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәтне узган җирле үзидарә органы тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 15 маддәсендә каралган ышанычны югалту белән бәйле эштән азат ителүче затлар реестрына кертелә;

**1.4. Нигезләмәнең 23 Бүлеге:**

23.1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бирергә:

«23.1. Муниципаль хезмәт стажына (гомуми) кергән эшләү (алмаштыру) чоры, шулай ук муниципаль хезмәт стажын исәпләү һәм билгеләү тәртибе 25.06.2013 елгы 50-ЗРТ номерлы муниципаль хезмәт турында ТР Кодексының 29 һәм 30 маддәләре белән көйләнә.»;

**1.5. Нигезләмәнең 26 Бүлеге:**

26.3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 3 абзац белән тулыландырырга:

««Выслуга лет өчен исәпләнгән һәм билгеләнгән пенсия акчасы составына вазифа оклады һәм классы чин өчен вазифа окладына ай саен бирелә торган өстәмә акча керә.».

**1.6 Нигезләмәнең тексты:**

27.1 бүлеген түбәндәге редакциядә биреп өстәргә:

«**27.1 Муниципаль хезмәт өчен килешү нигезендә кадрлар әзерләү.**

27.3 Муниципаль хезмәтнең югары квалификацияле кадрлар составын формалаштыру максатыннан, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәт өчен килешү нигезендә, РФ белем алу турында законы һәм “РФ муниципаль хезмәт турында” Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, кадрлар әзерли ала.

27.4 Муниципаль хезмәтне мәҗбүри үтәү белән бергә максатчан укыту турында килешү (алга таба – максатчан укыту турында килешү) җирле үзидарә органы һәм гражданин арасында төзелә һәм гражданинның укып бетергәннән соң күрсәтелгән җирле үзидарә органында билгеләнгән вакыт дәвамында муниципаль хезмәтне мәҗбүри үтүне күздә тота.

27.5 Максатчан укыту турында килешүне төзү конкурс нигезендә башкарыла.

27.6 Конкурс җирле үзидарә органы тарафыннан игълан ителә, һәм аны җирле үзидарә органында барлыкка килгән конкурс комиссиясе үткәрә.

27.7 Конкурс комиссиясе составына эш бирүченең вәкиле һәм (яки) вәкаләтле муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре бүлегеннән, юридик (хокукый) бүлектән, ә андый бүлекләр булмаган очракта – максатчан укыту турында килешү нигезендә гражданин тарафыннан муниципаль хезмәт үтәлергә тиешле җирле үзидарә органы эшчәнлегенә кадрлар һәм юридик (хокукый) ярдәм өчен җаваплы муниципаль хезмәткәрләр), шулай ук муниципаль хезмәт белән бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез эксперт-белгечләр буларак персональ мәгълүматны күрсәтмичә чакырылган гыйльми, белем бирү һәм (яки) башка оешмалар вәкилләре кертелә. Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

27.8 Конкурс комиссиясенең составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга тәэсир итәрлек мәнфәгатьләр низаглары чыгу мөмкинлеге булмаслык итеп формалаштырыла.

27.9 Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

27.10 Максатчан укыту турында килешү төзүгә конкурс үткәрү турында мәгълүмат муниципаль хокукый актлар рәсми бастырыла торган басма гавами мәгълүмат чараларында басыла, җирле үзидарә органның рәсми сайтында “Интернет” информацион-телекоммуникацион челтәрендә күрсәтелгән конкурс үтәкәрелергә бер айдан да соңга калмыйча урнаштырыла.

27.11 Әлеге маддәнең 8 өлешендә каралган конкурс үткәрү турында мәгълүматта уку беткәннән соң гражданнар тарафыннан алмаштырыласы муниципаль хезмәт вазифаларының төркемнәре; бу вазифаларга карата

квалификацион таләпләр; әлеге маддәненң 11 өлеше нигезендә конкурска бирелә торган документлар исемлеге, аларны кабул итү урыны һәм вакыты; күрсәтелгән документлар кайчанга кадәр кабул ителәсе вакыт; конкурс үткәрелү датасы, урыны һәм тәртибе; максатчан укыту турында килешү төзүгә кандидатларга бәя бирү һәм сайлап алу өчен файдаланыла торган конкурс процедуралары; язма биремнең темасы (әгәр конкурс процедураларының берсе язма бирем булган очракта), шулай ук башка информацион материаллар да булырга мөмкин.

27.12. Максатчан укыту турында килешү төзү конкурсында катнашу хокукына РФ дәүләт телен белүче һәм РФ бюджет системасының бюджет акчасы хисабына беренче мәртәбә көндезге бүлектә урта һөнәри яки югары белем алучы гражданнар ия. Күрсәтелгән конкурста катнашучы гражданин муниципаль хезмәткә алыну вакытына, шулай ук әлеге маддәнең 34 өлешендә каралган бөтен вакыт аралыгында муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыру өчен «РФ муниципаль хезмәт турында" Федераль законында билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

27.13 Конкурста катнашырга теләк белдергән гражданин җирле үзидарә органына:

1) шәхси гариза;

2) фотографияләр белән бергә муниципаль хезмәткә алынасы гражданин тарафыннан җирле үзидарә органына бирелә торган федераль закон нигезендә расланган форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;

3) паспорт копиясе (паспорт конкурска килгәндә шәхси бирелә);

4) хезмәт кенәгәсе копиясе яки гражданинның хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт эшчәнлеге моңа кадәр башкарылмаган очракларны исәпкә алмаганда);

5) гражданинның муниципаль хезмәткә алынуга һәм «РФ муниципаль хезмәт турында» Федераль закон нигезендә аны үтүгә каршы килми торган авыруның булмавы турында медицина оешмасының нәтиҗәсе;

6) гражданинның РФ бюджет системасының бюджет акчасы хисабына беренче мәртәбә көндезге бүлектә урта һөнәри яки югары белем алуын раслаучы , шулай ук ул үзләштерә торган белем бирү программасы (профессиянең, белгечлекнең яки әзерлек юнәлешенең исемен дә күрсәтеп) турында, уку планы нигезендә гражданинның аттестация үтү нәтиҗәләре турында, аның устав һәм белем бирү оешмасының эчке тәртип кагыйдәләрендә каралган йөкләмәләре турында мәгълүмат булган белешмә;

7)язма бирем (әгәр конкурс процедураларының берсе язма бирем булган очракта).

27.14 Җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән әлеге маддәнең 11 өлеше нигезендә гражданин тарафыннан бирелгән документларга кертелгән персональ һәм башка мәгълүматларның дөреслеге һәм тулылыгы тикшерелә.

27.15 Претендентлар сайлап алына һәм бәя бирелә торган конкурс комиссиясе утырышы әлеге маддәнең 11 өлешендә күрсәтелгән документлар кабул иткән соңгы көннән алып 14 календарь көнннән дә соң булмаска тиеш. Конкурс комиссиясе утырышының урыны, датасы һәм вакыты турында конкурс комиссиясе әгъзаларына конкурс комиссиясе сәркатибе мондый утырыш үтәсе көнгә өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә. Конкурс комиссиясе утырышын конкурс комиссиясе рәисе үткәрә, ә ул булмаганда –конкурс комиссиясе рәисе урынбасары.

27.16 Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда комиссия әгъзалары гомуми санының өчтән ике өлеше булса, үткәрелергә хокуклы.

27.17 Конкурс комиссиясе карарлары конкурс комиссиясе әгъзаларының утырышында катнашучылар тавышларының күпчелеге белән ачык тавыш бирү рәвешендә кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе утырышының рәисе тавыш биргән карар кабул ителә.

27.18 Конкурс комиссисе претендентларны әлеге маддәнең 11 өлеше 1 – 6 пунктларында күрсәтелгән документлар нигезендә, шулай ук конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча бәяли. Конкурс процедураларында җирле үзидарә органы нәтиҗәләре карары буенча индивидуаль әңгәмә, тест һәм (яки) язма бирем каралган.

27.19 Индивидуаль әңгәмә претендент белән аның булачак һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә караган тема буенча ирекле әңгәмә формасында үтә. Аның барышында ул, претендентның теоретик белемнәренә һәм шәхси сыйфатларына бәя бирү максатында, конкурс комиссиясе әгъзаларының сорауларына җавап бирә.

27.20 Претендентның теоретик белемнәренә һәм шәхси сыйфатларына бәя бирү түбәндәге критерийлар буенча башкарыла:

1) теоретик белемнәрнең дәрәҗәсе;

2) җавапның логикага нигезләп төзү;

3) грамоталылык һәм сөйләм культурасы;

4) претендентның белем бирү оешмасында өлгерү дәрәҗәсе, фәнни басмаларның булуы, фәнни конференцияләрдә, олимпиадаларда һәм башка белем бирү оешмалары үткәрә торган чараларда катнашу;

5) һөнәри мотивациянең булуы;

6) җирле үзидарә органнарында практика узу.

27.21 Индивидуаль әңгәмәнең нәтиҗәләрен конкурс комиссиясе әгъзалары түбәндәгечә бәяли:

1) өч балл, әгәр претендент тема эчтәлеген эзлекле итеп, тулы күләмдә ачса;

2) ике балл, әгәр претендент тема эчтәлеген эзлекле итеп, тулы күләмдә ачса, ләкин төгәлсезлекләр һәм юклы-барлы хаталар җибәрсә;

3) бер балл, әгәр претендент тема эчтәлеген эзлекле итеп, әмма бик үк тулы булмаган күләмдә ачса, төгәлсезлекләр һәм юклы-барлы хаталар җибәрсә;

4) ноль балл, әгәр претендент тема эчтәлеген ачмаса, шактый төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәрсә.

27.22 Претендентка индивидуаль әңгәмә нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары утырышында катнашучылар биргән баллар кушыла.

27.23 Претендентларга тест җирле үзидарә органы төзегән җирле үзидарә, муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы тору өлкәсендә РФ, ТР Конституцияләре нигезләмәләрен, РФ һәм ТР законнарын белүгә корылган теоретик сораулар, шулай ук максатчан укыту турында килешү нигезендә гражданин муниципаль хезмәт узасы җирле үзидарә органы эшчәнлеге өлкәсенә караган сораулар исемлеге нигезендә үткәрелә.

27.24 Тест нәтиҗәләре бәяләү конкурс комиссиясе тарафыннан претендентның тест сорауларына биргән дөрес җаваплары санынан чыгып башкарыла.

27.25 Тест нәтиҗәләрен конкурс комиссиясе әгъзалары түбәндәгечә бәяли:

1) биш балл, әгәр тест сорауларының 86 – 100 процентына дөрес җавап бирелсә;

2) дүрт балл, әгәр тест сорауларының 70 – 85 процентына дөрес җавап бирелсә;

3) өч балл, әгәр тест сорауларының 51 – 69 процентына дөрес җавап бирелсә;

4) ике балл, әгәр тест сорауларының 35 – 50 процентына дөрес җавап бирелсә;

5) бер балл, әгәр тест сорауларының 20 – 34 процентына дөрес җавап бирелсә;

6) ноль балл, әгәр тест сорауларының 20 процентыннан да ким дөрес җавап бирелсә;

27.26 Язма биремне претендент басма рәвештә конкурс комиссиясе билгеләгән һәм конкурс узу турында мәгълүматта күрсәтелгән тема буенча әзерли.

27.27 Язма биремнең темасы претендентның җирле үзидарә, муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы тору өлкәсендә РФ, ТР Конституцияләре нигезләмәләрен, РФ һәм ТР законнарын белүен, шулай ук максатчан укыту турында килешү нигезендә гражданин муниципаль хезмәт узасы җирле үзидарә органы эшчәнлеге өлкәсенә караган сорауларны белүен ачыкларлык итеп сайлана.

27.28 Язма биремне бәяләү критерийлары булып бирелгән теманы тулы итеп ачу, фикерне грамоталылы итеп бирү, язма сөйләм культурасы тора.

27.29 Язма бирем задание конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан түбәндәгечә бәяләнә:

1) өч балл, әгәр претендент язма бирем темасының эчтәлеген эзлекле итеп, тулы күләмдә ачса;

2) ике балл, әгәр претендент язма бирем темасының эчтәлеген эзлекле итеп, тулы күләмдә ачса, ләкин төгәлсезлекләр һәм юклы-барлы хаталар җибәрсә;

3) бер балл, әгәр претендент язма бирем темасының эчтәлеген эзлекле итеп, әмма бик үк тулы булмаган күләмдә ачса, төгәлсезлекләр һәм юклы-барлы хаталар җибәрсә;

4) ноль балл, әгәр претендент язма бирем темасының эчтәлеген ачмаса, шактый төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәрсә.

27.30Претендентка язма биремне бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары утырышында катнашучылар биргән баллар кушыла.

27.31 Конкурста җиңүче булып конкурс кысаларында кулланыла торган конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча иң күп санда балл җыйган претендент исәпләнә.

27.32 Конкурс комиссиясендә тавыш бирү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе утырышы рәисе һәм конкурс комиссиясе сәркатибе имзалаган беркетмәгә теркәлә.

27.33 Конкурс комиссиясенең конкурс җиңүчесен билгеләү турындагы карары җирле үзидарә органы белән конкурста җиңгән претендент арасында максатчан укыту турында килешү төзүгә нигез булып тора.

27.34 Конкурста катнашкан гражданнарга конкурс нәтиҗәләре турында язма рәвештә конкурс беткән көннән алып бер ай дәвамында хәбәр ителә.

27.35 Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнарны (проезд к месту проведения конкурс үтә торган җиргә бару һәм кайту, наемга тору урыны алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һ.б.) гражданнар үз акчалары хисабына күтәрә.

27.36 Максатчан уку беткәннән соң, муниципаль хезмәтне мәҗбүри узу вакыты максатчан укыту турында килешүдә билгеләнә. Күрсәтелгән вакыт җирле үзидарә органы максатчан укыту турында килешү нигезендә гражданинга социаль ярдәм чаралары тәкъдим иткән вакыттан аз булмаска тиеш.

27.37 Максатчан укыту турында килешү якларының йөкләмәләре һәм җаваплылыгы РФ законы нигезендә максатчан укыту турында килешү белән билгеләнә.

27.38 Максатчан укыту турында килешү гражданин белән бер мәртәбә төзелә.

27.39 Максатчан укыту турында килешүдә каралган чыгымнарны финанс яктан тәэмин итү җирле бюджет акчаары хисабына башкарыла.»;

2. Әлеге Карар рәсми рәвештә бастырылган көннән алып үз көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча ТР хокукый мәгълүмат Рәсми порталының рәсми сайтында, шулай ук http://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә ТР муниципаль берәмлекләр Порталында урнаштырылачак.

3. Әлеге карарның үтәлүен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башлыгы,
Буа муниципаль районы Советы рәисе М.А. Җәббаров